**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **31.10.2025 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Чубар-Абдул авыл җирлегенэ
керүче Буралы авылында 2026 елда
үзара салым жыюны кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,

- 1 төркем инвалидларыннан,
- көндезге уку формасында укучы студентлардан,
- махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан,
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы

гражданнардан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү.

2. Бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Чубар-Абдул авылы зиратын киртәләү өчен материал сатып алу)
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Җәлил ур., Октябрь ур., Пионер ур., Мәктәп ур. буенча грейдер белән юлларны тигезләү)
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Чубар-Абдул авылы юлларын һәм территорияләрен кардан чистарту)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, кабул ителгәннән соң, 10 көннән соң, соңга калмыйча түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Буралы авылы, Октябрь ур., 34 йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы: Н. Ә. Фәтхетдинов